**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 28 декабрендәге 5478 номерлы карары**

**Казан шәһәре Киров районының Краснококшайск урамындагы территорияне ызанлау проектын раслау турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, «Транспорт корылмаларын проектлау институты» акционерлык җәмгыяте гаризасы нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43, 45, 46 статьяларына, 2023 елның 10 июлендәге 305-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең гамәлдән чыгуын тану турында»гы федераль законның 8 статьясына, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 29 декабрендәге 5415 номерлы карары белән расланган Степан Халтурин, Краснококшайск, Зур Крыловка урамнары һәм Казансу елгасының иске үзәне белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына таянып, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 14 октябрендәге 4312 номерлы «Казан шәһәре Киров районының Краснококшайск урамындагы территорияне ызанлау проектын әзерләү турында»гы карарына туры китереп:

1. **Карар бирәм**:

1.1. Казан шәһәре Киров районының Краснококшайск урамындагы территорияне ызанлау проектын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга;

1.2. әлеге карарны, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган :ЗУ1 җир кишәрлеге координаталары исемлегеннән, инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитутлары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалану өчен материаллар) кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга;

1.3. әлеге карарны, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган :ЗУ1 җир кишәрлеге координаталары исемлегеннән, инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитутлары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалану өчен материаллар) кала, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга;

1.4. әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

2. «Транспорт корылмаларын проектлау институты» акционерлык җәмгыятенә **тәкъдим итәм**:

2.1. әлеге карарга кушымта нигезендә җир кишәрлеген дәүләт кадастр исәбенә кую өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә;

2.2. җир кишәрлеген дәүләт кадастр исәбенә куйганнан соң, җир кишәрлеген әлеге карарга кушымта нигезендә яңадан бүлү өчен тиешле документларны Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитетына тапшырырга;

2.3. әлеге карарга кушымтада күрсәтелгән җир кишәрлеген дәүләт кадастр исәбенә куйганнан соң, адреслы номер бирү һәм белешмәләрне Дәүләт адреслар реестрына кертү өчен Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенә җир кишәрлегенең кадастр номеры турында мәгълүмат тапшырырга;

2.4. җир кишәрлегеннән алга таба файдаланганда:

2.4.1. инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренең куркынычсызлыгын һәм әлеге челтәрләрне эксплуатацияләүче оешмаларның аларга тоткарлыксыз керүен тәэмин итәргә;

2.4.2. территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар өчен билгеләнгән чикләүләрне үтәргә;

2.4.3. «Казан шәһәре Елга аръягы бистәләренең XV – XVIII гасырлардагы мәдәни катламы» федераль әһәмияттәге истәлекле урын рәвешендәге мәдәни мирас объекты чикләрендә Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2023 елның 1 декабрендәге 956-п номерлы әмере, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2010 елның 1 апрелендәге 183 номерлы «Истәлекле урыннар территориясеннән файдалану характеры, әлеге территориядән файдалануга чикләүләр һәм Казан шәһәренең истәлекле

урыннары территориясендә хуҗалык эшчәнлегенә, проектлауга һәм төзүгә таләпләр турында нигезләмәне раслау хакында»гы әмере белән расланган чикләүләрне үтәргә;

2.4.4. Казан шәһәре төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлеге территориясе чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларына карата Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2017 елның 13 мартындагы 218од номерлы «Казан шәһәре төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлеге территориясе чикләрендә территория чикләрен, саклау предметын һәм шәһәр төзелеше регламентларына таләпләрне раслау турында»гы әмере белән расланган таләпләрне үтәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 28 декабрендәге
5478 номерлы карары белән
расланды

**Казан шәһәре Киров районының Краснококшайск урамындагы территорияне ызанлау проекты**

Казан шәһәре Киров районының Краснококшайск урамындагы территорияне ызанлау проекты түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

I. Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган :ЗУ1 җир кишәрлеге координаталары исемлеге, инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитутлары координаталары исемлеге белән территорияне ызанлау проекты турында нигезләмә.

II. Территорияне ызанлау буенча 1 номерлы сызым.

III. Территорияне ызанлау буенча 2 номерлы сызым.

IV. Территорияне ызанлау буенча 3 номерлы сызым.

Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган :ЗУ1 җир кишәрлеге координаталары исемлеге, инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитутлары координаталары исемлеге хезмәт урынында файдалана торган материаллар булып санала һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (ww.docskzn.ru) бастырылырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

## I. Территорияне ызанлау проекты турында нигезләмә

Казан шәһәре Киров районының Краснококшайск урамындагы территорияне ызанлау проекты 16:50:090590:498 һәм 16:50:090590:18 кадастр номерлы җир кишәрлекләре чикләренең бер-берсенә керүен һәм җир ашалыкны бетерү максатыннан әзерләнде һәм муниципаль милектәге 16:50:090590:498 кадастр номерлы, дәүләт милке чикләнмәгән 16:50:090590:18 кадастр номерлы җир кишәрлекләрен һәм дәүләт милкендәге

җирләрне яңадан бүлү юлы белән мәйданы 1546 кв.м булган җир кишәрлеге ясауны, шулай ук кызыл линияләрне гамәлдән чыгаруны күздә тота.

:ЗУ1 шартлы билгесе белән ясала торган җир кишәрлеге өчен рөхсәт ителгән файдалану төре – эшлекле идарә, ул 16:50:090590:498 кадастр номерлы беренчел җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төренә туры килә.


| **Ясала торган җир кишәрлегенең шартлы билгесе** | **Мәйданы, кв.м** | **Ясала торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Беренчел җир кишәрлекләренең кадастр номерлары** |
|---|---|---|---|
| :ЗУ1 | 1546 | Эшлекле идарә | 16:50:090590:498 |
| | | | 16:50:090590:18 |

Җир кишәрлегеннән алга таба файдаланганда:

- «Казан шәһәре Елга аръягы бистәләренең XV – XVIII гасырлардагы мәдәни катламы» федераль әһәмияттәге истәлекле урын рәвешендәге мәдәни мирас объекты чикләрендә Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2023 елның 1 декабрендәге 956-п номерлы әмере, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2010 елның 1 апрелендәге 183 номерлы «Истәлекле урыннар территориясеннән файдалану характеры, әлеге территориядән файдалануга чикләүләр һәм Казан шәһәренең истәлекле урыннары территориясендә хуҗалык эшчәнлегенә, проектлауга һәм төзүгә таләпләр турында нигезләмәне раслау хакында»гы әмере белән расланган чикләүләрне үтәргә;

- Казан шәһәре төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлеге территориясе чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларына карата Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2017 елның 13 мартындагы 218од номерлы «Казан шәһәре төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлеге территориясе чикләрендә территория чикләрен, саклау предметын һәм шәһәр төзелеше регламентларына таләпләрне раслау турында»гы әмере белән расланган таләпләрне үтәргә.


# II. Территорияне ызанлау буенча 1 номерлы сызым




## ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР:

| | |
|---|---|
| | гамәлдәге җир кишәрлекләре чикләре |
| | ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы ноктасы |
| н1 | чикнең характерлы яңа ноктасы номеры |
| | ызанлау проекты чикләре |
| | ясала торган җир кишәрлеге чикләре |
| | кызыл линияләр |
| | гамәлдән чыгарыла торган кызыл линияләр |
| | Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестры мәгълүматлары нигезендә капиталь төзелеш объекты |
| | инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты |
| | «Казан шәһәре Елга аръягы бистәләренең XV – XVIII гасырлардагы мәдәни катламы» төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты чиге. Казан шәһәре тарихи җирлеге чиге |
| :ЗУ1 | ясала торган җир кишәрлегенең шартлы билгесе |
| 16:50:090590:41 | Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестры мәгълүматлары нигезендә чиктәш җир кишәрлегенең кадастр номеры |
| 16:50:090590:18 | гамәлдән чыга торган беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры |
| 16:50:090590:501 | капиталь төзелеш объектының кадастр номеры |
| 16:50:090590 | кадастр кварталы билгеләнеше |


# III. Территорияне ызанлау буенча 2 номерлы сызым




**ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР:**

| | |
|---|---|
| | гамәлдәге җир кишәрлекләре чикләре |
| | ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы ноктасы |
| н1 | чикнең характерлы яңа ноктасы номеры |
| | ызанлау проекты чикләре |
| | ясала торган җир кишәрлеге чикләре |
| | кызыл линияләр |
| | гамәлдән чыгарыла торган кызыл линияләр |
| :ЗУ1 | ясала торган җир кишәрлегенең шартлы билгесе |
| 16:50:090590:18 | гамәлдән чыга торган беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры |
| 16:50:090590 | кадастр кварталы билгеләнеше |

# IV. Территорияне ызанлау буенча 3 номерлы сызым




## ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР:

| | |
|---|---|
| | гамәлдәге җир кишәрлекләре чикләре |
| ● | инженерлык коммуникацияләре сервитуты чигенең характерлы ноктасы |
| 1 | инженерлык коммуникацияләре сервитуты чигенең характерлы ноктасы номеры |
| | ызанлау проекты чикләре |
| | ясала торган җир кишәрлеге чикләре |
| | кызыл линияләр |
| | гамәлдән чыгарыла торган кызыл линияләр |
| | капиталь төзелеш объекты чиге |
| | инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты |
| :ЗУ1 | ясала торган җир кишәрлегенең шартлы билгесе |
| :ЗУ1/чзу1 | җир кишәрлеге өлешенең шартлы билгесе<br>(инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты) |
| 16:50:090590:501 | капиталь төзелеш объектының кадастр номеры |
| 16:50:090590 | кадастр кварталы билгеләнеше |